Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Бәтке авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

29 ноябрь 2021 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Бәтке һәм Көек авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан һәм 1нче төркем инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- Бәтке авылы Ленин урамы һәм Тынычлык урамы, Яншык авылы Мәктәп урамы, Кече Укмас авылы Комсомол урамы юллары ремонты өчен;
- МТЗ-82 тракторын тоту өчен;
- Яншык авылы зиратын әйләндереп алу өчен материаллар алуга;
- урам яктырту өчен лампочкалар сатып алу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәткеавыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы,23 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәис итүче Ф.М.Динмөхәмәтов

Бәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Динмөхәмәтов